КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1447

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче; 2019 ел, 21 май, 427 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче; 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы; 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы; 2020 ел, 1 апрель, 248 нче; 2020 ел, 27 май, 428 нче, 2022 ел, 31 март, 295 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр

тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.7$^{3}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7$^{3}$. Авыл җирлекләренә бер грант күләме 2,0 млн. сум тәшкил итә, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә - 2,5 млн. сум.»;

5.5$^{2}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5$^{2}$. Башка бюджетара трансфертны тотырга рөхсәт ителә торган чаралар исемлеге:

социаль әһәмиятле объектларда төзелеш-монтаж һәм ремонт эшләре (авыл мәдәният йортлары, һәйкәлләр, күперләр һ.б.);

авыл хуҗалыгы техникасы (трактор, печән чапкыч һ.б.) сатып алу;

юл-урам челтәрен ремонтлау (вак таш салу, чокырларны ремонтлау) һәм тротуарлар салу;

ял итү урыннарын төзекләндерү (парк, сквер, чишмә һәм башкалар (агачлар кисү, үлән чабу, агач тамырларын казып чыгарудан башка));

зиратларны төзекләндерү (коймалар тоту, чүп савытлары кую һ.б.);

балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;

сууткәргеч челтәрләрен төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау;

урам яктырткычларын урнаштыру һәм ремонтлау;

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин